Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Тайсуган авыл Советы

КАРАРЫ

20 февраль 2023 ел №67

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл Советының 2022 елның 24 маендагы 44 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авылы җирлеге территориясендә җирләү эшен оештыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды турында» 2022 елның 14 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

Тайсуган авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл Советының 2022 елның 24 маендагы 44 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авылы җирлеге территориясендә җирләү эшен оештыру турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга кушымтада:

8 пунктның 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен, Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча пенсия һәм социаль иминият фонды бүлеге, Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты белән килештереп, раслый.

2. Әлеге карарны Тайсуган авылы, Сәләхетдинов урамы,36б йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл башлыгына йөкләргә.

Тайсуган
авыл җирлеге башлыгы М.Ф.Мостафин